СОВЕТ
МАСАДИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
423753, д. Масады,ул.Нефтяников, д.18
Тел. 3-44-49

АКТАНЫШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МӘСӘДЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423753, Мәсәде авылы Нефтяниклар ур.,18нче йорт.
Тел. 3-44-49

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«12» июль 2021 ел №12

## Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 27 июлендәге 14-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл җирлеге Советының 20.06.2016 ел, № 8 карары белән расланган, Актаныш муниципаль районы Мәсәде авыл җирлегенең бюджет процессы нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 15 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «3. Агымдагы финанс елына һәм план чорына бюджетка үзгәрешләр керткәндә чираттагы финанс елында тиешле бюджет керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган федераль законнар, Россия Федерациясе субъектлары законнары, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары муниципаль хокукый актлары нигезләмәләре исәпкә алына».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Мәсәде авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Актаныш муниципаль районы
Мәсәде авыл җирлеге Советы рәисе Минһаҗетдинова Ф.Р.